КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 май г.Казань № 442

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 июль, 548 нче карары белән расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 4 июль, 548 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 декабрь, 1162 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм технопаркларның җитештерү һәм инновация компанияләрен булдыру (үстерү) максатларында, кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларына җитештерү мәйданнарыннан һәм урыннарыннан ташламалы файдалана алу мөмкинлеге бирүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен сәнәгать (индустриаль) паркларының һәм (яки) технопаркларның идарә итүче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 17[1] нче пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«17[1]. Бу Тәртип яки субсидия бирү турындагы килешү нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү вакыты җитү яки башка йөкләмәләрне үтәү Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-2019) таралу шартларында югары әзерлек режимы гамәлдә булган чорга туры килсә, Министрлык сәнәгать (индустриаль) паркының һәм (яки) технопаркның идарә итүче компаниясе тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү яки башка йөкләмәләрне үтәү вакытын 12 айга күчерү турында карар кабул итәргә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин